Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № I-3**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 22 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 48 статьясы нигезендә Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елның 16 октябренә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурска дәгъва кылучылардан документлар кабул итү 2015 елның 25 сентябреннән 2015 елның 14 октябренә кадәр түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык бистәсе шәһәр тибындагы поселогы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, Ленин ур., 48, каб. №23.

2. Конкурс комиссиясенә конкурсны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2010 елның 15 октябрендәге I-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә 2015 елның 16 октябрендә 10:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында үткәрергә: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык бистәсе шәһәр тибындагы поселогы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, Ленин ур., 48 йорт һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссиясе составының яртысын 3 кеше составында кушымта

нигезендә расларга.

4. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 декабрендәге ПУ-1164 номерлы Указын исәпкә алып, расларга:

– Леонов Владимир Александровичны – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрын – конкурс комиссиясе рәисе итеп (килешенү буенча);

–Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдифовнаны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү һәм Мәдәният идарәсе башлыгын – конкурс комиссиясе рәисе урынбасары итеп (килешенү буенча)

–Шелкова Светлана Александровнаны – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгын – конкурс комиссиясе сәркатибе итеп.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында хәбәрне «Авыл офыклары»район газетасында бастырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2015 елның 22 сентябрендәге
I-3 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссиясе составының яртысы**

| | |
|---|---|
| Исмәгыйлев Рафаэль Дәүләтьярович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе, конкурс комиссиясе әгъзасы |
| Шелкова Светлана Александровна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы, конкурс комиссиясе сәркатибе |
| Җамалиев Рөстәм Рәсимович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы, конкурс комиссиясе әгъзасы |